وَاعْتَصِمُوا بِحَبْلِ اللَّهِ جَمِيعًا وَلَا تَفَرَّقُوا

Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!

6+

# Дин вә Мәгыйшәт

№24 (167). 14 декабрь 2012 / 1-сәфәр-1434

ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



Казан басмасы нәшер ителүгә 225 ел тулу уңаеннан "түгәрәк өстәл" узды

▷2◁



Рухи тамырларыбыздан читләшмик!

▷2◁



Япониягә ислам динен ирештергән шәхес

▷4◁

# Диния нәзарәте: 2012 елда

## Хөрмәтле дин кардәшләребез!
## Әссәламегаләйкүм вә рахмәтуллаһи вә бәракәтүһү!

**Башкарган эшләребезгә берникадәр нәтиҗә ясый, киләчәккә яңа максатлар куя торган вакыт – агымдагы елга йомгак ясар чак җитте.**

Бүгенге көндә дин әһелләренә күпгасырлык ислам дине тарихы-мирасы булган Татарстанда дини эшчәнлекне нинди шартларда оештыруны, алып баруны аңлау, дөрес күзаллау бик мөһим. Татарстан Россия күләмендә толерантлык белән көчле, бу үзе үк зур шарт, таләп, җаваплылык булып тора. Моннан тыш, дөнья күләмендәге хәлләр безгә дә килеп җитте. Белгәнебезчә, чит илләрдә каршылыклы вакыйгалар китереп чыгаралар. Мөселманнар дөньясында бик катлаулы һәм күптөрле үзенчәлекләргә ия процесслар бара. Дистәләгән мөселман илләрендә төрле җәнҗаллар чыга, мөселманнарга бөтенләй хас булмаган гамәлләр кылына.

Әйтик, Ливиядә җирле халыклар үзара сугыша, үтерешә, Нигериядә, Суданда төрле дини агымнарның каршылыклары күзәтелә. Чит илләрдәге вакыйгаларның Россиягә дә йогынтысы сизелә. Динебезгә дошман булганнарның, экстремистик агымнарның куркыныч сәясәте бу йогынтыны тагын да арттыра. Әлбәттә, дәүләт Исламны үстерүгә уңайлы шартлар тудырырга омтыла, мәчетләр салыну белән бергә дини мәгариф, мәгълүмат юнәлешендә күп эшләр башкарыла.

Шул ук вакытта кыенлыклар күзәтелә, мөселманнарның рәсми оешмаларына радикал юнәлешләр тарафыннан информацион, җинаятьчел төсмердәге һөҗүмнәр оештырыла. Әгәр Россия күләмендә карасак, үтеп барган елда берничә танылган остаз, имам үтерелде. Шулар арасында Сәет әфәнде әл-Чиркави да, Вәлиулла хәзрәт тә бар. Шушы коточкыч хәл Татарстанга да килеп җитәр дип күпләр уйламады да. Татарстандагы җәйге фаҗигале хәлләр күпләрнең нинди ниятләр белән йөрүен күрсәтте. Аерып әйткәндә, кемнәрнең Россиягә читтән кертелгән ят, безгә хас булмаган экстремистик идеология белән көрәшүен, кемнәрнең ислам дине сүзе артына качып җәнҗаллар куптаруын, тавыш чыгаруын һәм бәхәсләр тудыруын күрдек.

Бүгенге Россия күпмилләтле һәм күпдинле ил. Шул сәбәпле, дин әһелләренең хәленә керү, дин өлкәсендә конфликтларга юл куймау, аны булдырмый калу чараларын күрү - ил җитәкчесенең бурычы булып тора. Хөкүмәт белән дин әһелләре арасында үзара килешүгә корылган дустанә мөнәсәбәтләр дини эшчәнлекне уңай шартларда алып баруга ярдәм итә. Безнең республика җитәкчелеге, Президент Рөстәм Миңнеханов та шушы яклы.

2012 елда Коръәннең "Казан басмасы" басылуга 225 ел тулу уңаеннан, мирасыбызны барлау һәм динебезне пропагандалау ниятеннән агымдагы елны "Татарстанда Коръән елы" дип игълан иттек. Май аенда Кол Шәриф мәчетендә Коръән хәтем кылынып, бөтен Татарстан һәм Россия мөселманнары өчен дога кылынды һәм дөньядагы иң зур Коръән быел Болгар шәһәрендә сафка баскан Истәлек билгесенә күчерелде. Тарихи-мәдәни мирас елы кысаларында игълан ителгән Коръән елы уңаеннан республикабызда үткән чаралар зур игътибарга һәм киләчәктә дә дәвамлы булырга лаек. Коръән елы кысаларында үткәрелгән "түгәрәк өстәл"ләргә, фәнни-гамәли конференцияләргә фән һәм дәүләт эшлеклеләре, каләм әһелләре, табиблар, хокук белгечләре һәм башка өлкәләрдән белгечләр җәлеп ителде. Кыскасы, игълан ителгән Коръән елы мөселманнарның Изге китабы - Коръәнгә игътибарны һәм ихтирамны арттырды, күп кенә мәсьәләләрне уртага салып фикер алышырга этәргеч булды. Бу - үтеп бара торган елның иң зур казанышы дип әйтү дә артык булмастыр, мөгаен.

Икенче яктан, кызганыч, ел авыр хәлләр белән дә истә калды.

Май аенда без барчабыз Россиядән һәм чит илләрдән килгән кунаклар белән бергә Болгарга җыелып, күтәренке рух белән бирелә яңа төзелгән Ак мәчет ачылышында катнаштык, июнь аенда Изге Болгар җыенын бик күркәм итеп уздырдык. Кызганыч, барча мөселманнар июль аенда көтеп алган рамазан ае (үзегез дә ишетеп, күреп тордыгыз) өстәмә авырлыклар - кыенлыклар тудырган җинаятьчел вакыйгалар белән үрелде. Әлбәттә, бу вакыйгалар ил-көнебезнең тынычлыгын алды, нәтиҗәдә, дин әһелләренә четерекле шартларда эшләргә туры килә. Шушы хәлләр аркасында билгеле шәхес, күп еллар дәвамында дин өлкәсендә зур тырышлыклар куйган, күренекле дин әһеле Вәлиулла хәзрәт Якуповның атып үтерелүе, әлбәттә, иң аянычы, тетрәндергәне булды. Аллаһы Тәгалә Вәлиулла хәзрәтнең рухын шат кылсын. Аны шәһитләр җөмләсеннән кабул кылса иде.

Бүгенге көндә республикабызда традицион хәнәфи мәзһәбен пропагандалау юнәлешендә күп эшләр башкарып киләбез. Алга таба да бу эшчәнлек дәвам итәр.

*(Ахыры 3 нче биттә.)*

# Иман һәм вакыт

**Сәхабәләр, бүгенге көндә күп кенә мөселманнар яттан белгән сүрәне укып бетерми торып, таралышмаганнар. Бу сүрә сәхабәләр өчен шигарь (девиз) булган һәм шуңа да алар аны шулай еш укыганнар. Бу очракта сүз Коръәндәге "Гасыр" сүрәсе турында бара. Гасыр - йөзьеллык, гомумән, замана, вакыт, чор, дәвер мәгънәләрен үз эченә ала. Аның беренче аятендә (мәгънәсе): "Гасырлар исеме белән ант итәмен ки", - диелә.**



Бу сүрә Аллаһы Тәгаләнең икенде намазы вакыты белән ант итүеннән башланып китә. Вакыт - бар әйберләр өчен дә хас булган дүрт үлчәмнең берсе. Аллаһы Тәгалә яраткан һәр әйбер дә вакыт йогынтысына насыйп ителә, ягъни һәрберсенең дә башы (әүвәлге халәте) бар һәм дә ул ахыргы ноктага таба хәрәкәт итә. Һәр яратылганга нindидер бер вакыт аралыгы бирелгән. "Кеше - ул Вакыт", - ди галимнәр. Моңа иң гүзәл билгеләмәне имам Хәсән әл-Басри биргән: "Чынлап та, кеше билгеле бер сандагы көннәрдән генә тора. Һәр үтеп киткән көн белән бергә, ул бу кешедән дә кими".

Һәрбер сәгать, һәр минут, һәр секунд саен без үзебезнең тормыш азагына - үлемебезгә якынаябыз. Кешенең төп капиталы - вакыт. Вакыт - без кадерен белмәгән төп байлык. Вакыт безне тормышыбызның иң мөһим моментына - безнең бу дөньядан икенчесенә күчү мизгеленә алып бара. Әгәр дә безнең үлгәч ни көтәсен белү буенча ныклы ышануларыбыз булса, бик сирәкләребез генә төнлә йоклый алган булыр иде. Без һәрберебез дә: "Безнең барыбызны да алда үлем көтә", - дип әйтәбез, ә килеп җитәчәк ул сәгатьнең никадәр җитди булуын аңлап бетермибез. Үлем - кире кагып булмый торган факт; тормышны да, үлемне дә Аллаһы Тәгалә Үзе яраткан. Аллаһы Тәгалә Коръәндә (мәгънәсе): "Аллаһ кемнең игелек кылачагын сынап карар өчен, үлемне, яшәеш-тормышны бар итте. Аллаһ - җиңү белмәс кодрәт иясе, чиксез мәрхәмәтле ярлыкаучы" ("Мөлек (Падишалык)" сүрәсенең 2 нче аяте), - дип белгертә. Шунысына да игътибар итәргә кирәк: Аллаһы Тәгалә "үлемне һәм тереклекне бар кылып", иң әүвәл үлемне искә ала. Бу - үлемнең, мәңгелек дөньяга күчү мизгеленең мөһимлеге,

*(Ахыры 2 нче биттә.)*

## ЯҢАЛЫКЛАР

### "АПРЕЛЬ"ДӘ ИНВАЛИДЛАР ДЕКАДАСЫ ТӘМАМЛАНДЫ

**11 декабрь көнне "Апрель" реабилитацион үзәгендә Инвалидлар декадасы тәмамланды.** Бу уңайдан оештырылган чарада үзәккә йөрүче балалар, аларның ата-аналары һәм иганәчеләр катнашты. Үзәк даими ярдәм күрсәтүчеләргә - Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең хәйрия һәм ярдәм күрсәтү бүлеге җитәкчесе Гөлнара Садыйковага, ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтаховка, "Эфир" телекомпаниясе вәкилләренә "Рәхмәт хатлары"н тапшырды.

"Апрель" реабилитацион үзәге директоры Наталья Трифонова Татарстан мөфтие Илдус хәзрәт Фәизгә аерым зур рәхмәтен белдерде һәм үзәк хезмәткәрләре, балаларның әтиәниләре аның тизрәк сәламәтләнүен теләп, догалар укуын әйтте. Мөфтият вәкилләре үзәккә йөрүчеләргә Инвалидлар декадасы тәмамлану уңаеннан һәм туган көннәре октябрьгә, ноябрьгә туры килгәннәрне котлап, бүләкләр тапшырды.

### ТҮБӘН КАМАДА МӘЧЕТ ТӨЗЕЛЕШЕ ДӘВАМ ИТӘ

**11 декабрь көнне Түбән Кама шәһәрендә төзелә торган яңа мәчет манарасына балкон плитәләре куелды.**

Баш инженер Камил Шәрәфетдинов сүзләренә караганда, биш метр диаметрлы плитәләрнең авырлыгы 12,5 тонна тора. "SOP&G" компаниясе белгечләре куелган максатларга ирешкән: плитә яхшы итеп урнаштырылган. Төзүчеләр 2013 елның гыйнвар аенда ай куярга ниятлиләр.

### ШӘКЕРТЛӘР К.НАСЫЙРИ МУЗЕЕНДА БУЛДЫ

**12 декабрь көнне Казан ислам колледжының I курс студентлары танылган мәгърифәтче-галим, тарихчы-этнограф, тел белгече һәм язучы Каюм Насыйриның (1825-1902) музей-йортында (Париж Коммунасы урамы, 35) булып кайтты.** Әлеге йортта галим 1889-1902 елларда яшәгән. Белгәнебезчә, кырыктан артык әсәре белән билгеле Каюм Насыйри хәнәфи мәзһәбенең төп нигезләрен аңлаешлы формада җиткергән галимнәрдән санала.

### "ТАЯН АЛЛАГА" КОНКУРСЫНА НӘТИҖӘ ЯСАЛАЧАК

**18 декабрьдә III "Таян Аллага" әдәби конкурска нәтиҗәләр ясалачак.** Бу чараның төп максаты - татар яшьләре арасында талантларны эзләү һәм аларның игътибарын Исламга җәлеп итү. Тантаналы чарада конкурста катнашучыларга һәм җиңүчеләргә бүләкләр тапшырылачак. Тәҗрибәле жюри заман яшьләренең әдәби талантына бәя бирәчәк. Конкурс нәтиҗәләре буенча яшь авторларның әдәби әсәрләреннән торган җыентык нәшер итү планлаштырыла.

*Мәгълүматлар ТР мөселманнары Диния нәзарәтенең рәсми сайтыннан (www.dumrt.ru) алынды*

**ГАЗЕТАЛАРГА ЯЗЫЛЫРГА ОНЫТМЫЙК!**

**1 сентябрьдән 2013 елның I яртыеллыгы өчен "Дин вә мәгыйшәт" (язылу индексы - 16046) һәм "Умма" (83072) газеталарына язылу башланды. 6 айга язылу бәясе - 118,38 сум.**

# Казан басмасы нәшер ителүгә 225 ел тулу уңаеннан "түгәрәк өстәл" узды

**13 декабрь көнне Казанның Мәрҗани мәчетендә Россиядә беренче басма Коръән - Казан басмасы нәшер ителүгә 225 ел тулуга багышланган һәм Татарстанда Коръән елы ахырына якынлашып килү уңаеннан "түгәрәк өстәл" утырышы узды.**

Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан оештырылган чарада Татарстан мөфтиенең беренче урынбасары Габдулла хәзрәт Әдһәмов, ТР Дәүләт Советы депутаты, танылган җәмәгать эшлеклесе Фәрит Мифтахов, КФУдагы Шәрыкны өйрәнү һәм халыкара мөнәсәбәтләр институтының төбәкне һәм Исламны өйрәнү кафедрасы мөдире Ренат Беккин, дин белгече Фәрит хәзрәт Сәлмән, язучы Рабит Батулла һәм башкалар катнашты.

Беренче Коръән басмасы Екатерина Икенченең 1787 елгы карары нигезендә дөнья күрә. Гарәп графикасы нигезендә шрифтлар татар дин әһелләре тарафыннан ясала. Нәкъ шул хәрефләр нигезендә Коръәннең мәшһүр Казан басмасы барлыкка килә.

Коръән елында Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте көче белән Коръәни-Кәримнең Казан басмасы - яңа юбилей нөсхәсе нәшер ителде. Изге Китап ун мең данә басылып, дин әһелләренә, зыялыларга бушлай таратылды. Ел дәвамында мөхтәсибәтләрдә балалар арасында Изге Китапны уку бәйгеләре оештырылды. 1 декабрь көнне Россия ислам университетында Республикакүләм Коръән укучылар бәйгесе узды. Республика мәчетләрендә балалар өчен Коръән аятьләрен ятлау курслары, "Коръән бүләк ит" хәйрия акцияләре үткәрелде.

Утырышта бүгенге вакыйганың мөселман өммәтеннән булган барлык затлар өчен бик әһәмиятле булуы ассызыклап үтелде һәм катнашучылар игътибарына республикада Коръән елы кысаларында үткәрелгән чаралар чагылыш тапкан видеоролик тәкъдим ителде.

Габдулла хәзрәт Әдһәмов утырышта катнашучыларны шәхсән һәм мөфти Илдус хәзрәт Фәиз исеменнән сәламләп, Коръән иңдерелү белән бәйле кыйссаның эчтәлеген сөйләде. "Адәм баласы заманында бик гөнаһлы була, көннәрдән-беркөнне өенә кайтып барганда, җирдә яткан бер кисәк кәгазь күрә, әмма гарәп язуы хәрефләрен таный алмый. Шулай да язуга хөрмәт күрсәтеп, өенә алып кайтып, кәгазьне хушбуйлар белән сөртеп, өскә, кадерле урынга куя. Өзектә Аллаһы Тәгаләнең исемнәре искә алынган була. Шул төнне бу кеше төш күрә: төштә Аллаһы Тәгаләнең үзенә мөрәҗәгать итүен ишетә. Аллаһы Тәгалә әйтә: "Син безгә хөрмәт күрсәткән күк, без дә сине әүлиялар дәрәҗәсенә күтәрәбез", ди. Шул көннән башлап, бу кеше тәүбәгә килеп, Аллаһы Тәгаләгә якыная. Бу кыйсса аркылы без Аллаһы Тәгаләнең безгә Коръән иңдерү әһәмиятенә төшенәбез. Ничә еллардан бирле Аллаһы Тәгалә Коръәни-Кәримне Изге Китап итеп кадерләргә ярдәм итә. 2012 елда Диния нәзарәте дә моңа үз өлешен кerткәндер дип ышанасы килә. Милләтебез һәрвакыт Коръән белән бәйле булды, татарлар Изге Китапка хөрмәт белән карый. "Ул бит китапта язылган" дип сөйләргә ярата. Милләтебездә Коръәнгә аерым хөрмәт урнашты ", - дип белдерде Г.Әдһәмов.



Ходайга шөкер, мәчеттә вакытта гына түгел, ә иҗтимагыйсәяси тормышта да Коръән принципларына таянып эшләүче, мөселман халкына хезмәт күрсәтүче иҗтимагый-сәяси эшлеклеләр бар. ТР Дәүләт Советы депутаты Фәрит Мифтахов утырышта шулай дип сыйфатланды. Ул билгеләп узганча, Диния нәзарәте һәрвакыт Исламда хатын-кызның тоткан урыны, сәламәтлек, дин һәм дәүләт Конституциясе белән бәйле мәсьәләләрне яктыртырга тырышып, төрле "түгәрәк өстәл" утырышларын оештырып килде. "225 ел элек Россия күләмендә беренче тапкыр Аллаһы Тәгалә ярдәме белән Казанда Коръән басылды. Безгә киләчәктә дә Коръән белән яшәргә насыйп булса иде", - дип белдерде Фәрит Мифтахов.

Казан шәһәре имам-мөхтәсибе Мансур хәзрәт Җәләлетдин сүзләренә караганда, узган гасырның 80 нче елларында Коръәннең Казан басмасы бик дефицит булып, аны теләсә-нинди бәягә сатып алырга әзер торучылар булган. Мансур хәзрәт 1978 елда Изге Китапның 5 меңләп тираж белән дөнья күрүен дә билгеләп узды. Ничек кенә булмасын, укырга уңайлы дип танылган Казан басмасы бөтен дөнья буенча таралган...

Узган "түгәрәк өстәл"дә дин белгечләре Коръән мәгънәләрен тәрҗемә итү проблемалары, Изге Китап текстларын фәнни яктан өйрәнү кебек мәсьәләләр буенча да фикер алышты.

**Гөлнар ГАРИФУЛЛИНА**



# Рухи тамырларыбыздан читләшмик!

**Кызганыч ки, Татарстанда ислам дине яңарышы бик катлаулы төстә барды. СССР таркалгач, дингә юллар ачылды. Әмма Россиядә дини белем алу өчен мөмкинлекләр юк иде. Мәдрәсәләр яңартылмаган, аларда укытырдай хәзрәтләр дә санаулы гына. Мәктәп тәмамлаган яшьләр чит илләргә белем эстәргә китте. Дин турында аз гына да гыйлеме булмаган егетләр үзенә кирәклесен дә, безгә кирәкмәгәнен дә сеңдереп, Татарстанга кайтты, яшьләрне укыта башлады. Билгеле, аны "Террорчы бул" дип өйрәтмәгәннәр.**

Әмма ул тегендәге традицияләрне бирегә кайтып аңлата башлады. Ә Согуд Гарәбстанында хәнбәли мәзһәбе нигезендә яшиләр. Бу илдә гел мөселманнар гына булгач, алар ислам диненә хас булмаган күп әйберләрне кискен рәвештә инкяр итә. Ә бездә җирлек башка. Синең тирәңдә икенче дин, башка милләт кешеләре дә яши. Аларның да дөньяга үз карашы бар. Шуңа күрә биредә хәнәфи мәзһәбе тамырланган. Ә ваһһабчылыкның идеология буларак тискәре ягы - безгә яки биредә яшәүче халыкка хас булмаган, бу җирлектән аерылган традицияләрне тарату, халыкны мең еллык традицион тамырларыннан аеру. Ваһһабчылар, дип әйткәндә, алар бу җирлектән аерылган кешеләр, дип аңларга кирәк. Ә традицион җирлектән аерылу - радикальлек өчен иң беренче һәм куркыныч адымнарның берсе.

Ислам дигән төшенчә бер Аллаһка инануны аңлата. Без, хәнәфи мәзһәбендәгеләр, шулай дибез. Ваһһабчылар исә, чиста Ислам - Мөхәммәд саллә-ллаһу галәйһи үә сәләм чорына кайту дип, бер Аллага инануны абсолютлаштыралар. Ә бу исә кайбер әйберләрне тыюга китерә. Әйтик, син әбибабаң, ата-анаң каберенә йөрмәскә, изгеләр җирләнгән урыннарга бармаска тиеш буласың. Бу тыюлар Согуд Гарәбстанында яшәгән, традицияләре чүл шартларында формалашкан халык өчен кыенлык тудырмый. Ул чүлдә сәфәр кыла, якыны вафат булса, шунда ук җирләп китә, соңыннан ул каберне таба да алмый. Шуңа да якыннарың күмелгән урынга мөнәсәбәт дигән төшенчә алар өчен гомумән юк. Ә бездә башкача. Күз алдына китерегез, авылда яшәгән, үзен чиста Ислам тарафдары санаган мөселман көн дә, зират яныннан узып, мәчеткә йөри, әмма зиярәт кылмый. Гыйлемле, биш вакыт намаз укый торган бу мөселманның ата-бабасы кабере өстендә агачлар ауган, анда чүп-чар ауный икән, аның халык арасындагы абруе бер тиенлек тә булмаячак. Чынлыкта, дингә инану телдә генә түгел, ә әхлакый йөзендә дә булырга тиеш. Аннары мәетнең өчесе, җидесе, кырыгын үткәрүүткәрмәү мәсьәләсен бик куерталар. Янәсе, мондый мәҗлесләргә йөрмә. Югыйсә, ислам динендә рациональлек дигән әйбер бар. Мин бу уңайдан үзебезнең Балтач ягын күз алдыма китерәм. Бөтен туган-тумача җыела. Кешенең йөрәге ихлас сөйләшү өчен ачылган, ул якын әрвахлар рухына Коръән укыту өчен иң тәмле ризыклар тезелгән табын янына килеп утырган. Бу инде муллага вәгазь уку өчен әзер аудитория. Алай гына да түгел, алар бу дөньяның вакытлы гына булуы, Аллаһ каршына барырга туры киләчәге турында уйлана. Ә инде мондый мәҗлесләрне инкяр итү - җыелган халыкны, ягъни әзер аудиторияне инкяр итү дигән сүз. Башкача аларны ничек җыясың? Ваһһабчылыкның кайбер җирлектә, әйтик, әлеге дә баягы Согуд Гарәбстанында бер зыяны да юк. Ә бездә ул күп аңлашылмаучылык тудыра. Чит традицияләрне аңсыз рәвештә безнең җирлеккә күчерү - ваһһабчылыкның иң тискәре ягы. Вафат булган кешенең өчесен, җидесен, кырыгын уздыру вакытындагы Коръән уку, вәгазь сөйләү, сәдака бирүдә ислам диненә хилафлык китергән бер әйбер дә юк. Бу - авылда халык белән эшләү өчен нәтиҗәле алымнарның берсе.

Мәсьәләнең икенче ягы да бар. Безнең хәнәфи мәзһәбендә намаз укыганда куллар кендектән түбән куелырга тиеш, без кулларны күтәреп намаз укымыйбыз. "Ул мәчеткә йөри, ничек укыса да, ярар инде", дип әйтәләр. Болай дию дә дөрес түгел. Дөрес, формаль килсәк, биредә дин кануннарын бозу юк. Ихлас күңелдән укылган намазны Аллаһы Тәгалә кабул итәр. Әмма дин - ул традиция. Кеше үзе шулай укыгач, мин хаклы, дип уйлый башлый. Ә инде тора-бара минем бабамнар намазны дөрес укымаган, аларның традицияләре миңа нәрсәгә, татар телен ник өйрәним, йола, гореф-гадәтләр нигә кирәк, миңа ничек өйрәттеләр, шулай яшим дип, ул бүтән традицияләрне үз итә башлый. Шуңа күрә биш вакыт намазын калдырмаган, әмма шул ук вакытта үз телен, йола, гореф-гадәтләрен, үткәннәрен инкяр иткән яшьләр тәрбияләвебез мөмкин. Аның: "Әти-әни намаз укымый", - дип, алар белән утырып ашамый башлавы да ихтимал. Бер газетада намаз укучы студент егет белән уздырылган интервью укыган идем. "Минем әти-әни намаз укымый, алар - кяферләр", - ди ул. Үз ата-анасын кяфер дип әйткән яшьләр белән нишләрбез? Ә үзе шулар акчасына яшәп белем ала икән. Без еш кына: "Аллаһка шөкер, балабыз эчми, тартмый, намаз укый", - дип шатланабыз. Ә ул: "Сез намаз укымыйсыз, миңа сезнең белән утырып ашау хәрам", - дисә... Әйе, алар ихлас күңелдән Аллаһы Тәгаләгә бирелгән яшьләр. Шуңа күрә яшьләрне биздерү дә бик ярап бетми. Алар белем алырга чит илгә барган һәм нинди остаз туры килгән, шуннан өйрәнгән. Әйткәнемчә, аның иң куркыныч ягы - безнең җирлектән аерылып, манкортка әверелү, радикальләшеп китү ихтималы булу.

**Рәфыйк МӨХӘММӘТШИН,**
**сәясәт фәннәре докторы,**
**Россия ислам университеты ректоры**

# Иман һәм вакыт

***(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)***

аның әһәмиятле булуы турында сөйли. Үлем - без бу мизгелдә сайлап алу мөмкинлегенә ия булуы белән мөһим. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (сгв) әйткән: "Аллаһның бөеклеге белән ант итәм, бу фани дөньядан соң - оҗмах яки тамугтан тыш - башка яшәр урын юк" (Хәмзәт бине Һөмрәннән "Җәмигу әс-сәгыйрь"). Беркем дә Оҗмах белән Тәмуг арасындагы урталыкны сайлый алмый.

Үлемнең әһәмиятлелеген аңлау һәркемдә (аның Аллаһка ышануы һәм үз инанулары буенча) төрлечә. Шуңа да Аллаһы Тәгалә вакытның мөһимлеген ассызыклап, алда әйтеп кителгән аятьтә ант итә.

Аннан соң Ул (мәгънәсе): "Кеше һәрвакыт уңышсызлыкка очрый" ("Гасыр" сүрәсенең 2 нче аяте), - ди. Вакытны үткәрү буенча кешеләр ике төргә бүленә. Беренчеләре - вакытны ашау, йоклау, төрле тамашалар карап ләззәтләнү өчен сарыф итә, бу тормыштан барысын да тулысынча алып калырга тели. Үзенә бирелгән вакытның кадерен белмичә, тормышын бушка әрәм итә. Андый кеше Җирнең хайваннар дөньясындагы башка вәкилләреннән бер ягы белән дә аерылмый. Кешеләрнең икенче төрләре бу тормышның кадерен белә, аның Аллаһы Тәгалә тарафыннан бирелгән бердәнбер мөмкинлек икәнен, үлемнең кисәк кенә килгәнен дә яхшы аңлый. Аллаһка инану төрлечә була, шуңа да Аллаһы Тәгалә (мәгънәсе): "Бары тик иман китереп, игелек кылганнар гына, бер-берләренә Хакыйкатьне исбат иткәннәр, бер-берләренә түзем, сабыр булырга өндәгәннәр генә зарарлануда, кимчелектә, хәсрәттә булмаслар" ("Гасыр" сүрәсенең 3 нче аяте), - ди.

**Руслан хәзрәт МОРТАЗИН,**
**Татарстанның**
**төньяк-көнчыгыш**
**төбәге казые,**
**Актаныш Җәмигъ**
**мәчете имам-хатыйбы**

# Диния нәзарәте: 2012 елда

*(Ахыры. Башы 1 нче биттә.)*

Нәзарәт, берниндн каршылыкларга карамастан, үз эшчәнлеген актив төстә алып баруын дәвам итә. Агымдагы елда үткәрелгән чараларның берничәсен генә атап китү дә моны ачыктан-ачык күрсәтеп тора: Коръән елы кысаларында "Казан басмасы" нәшер ителде һәм барлык имамнарга, зыялыларга таратылды; беренче тапкыр Казанда республикабыздагы дин әһелләренең барысына да имам-хатыйблык шәһадәтнамәләре тапшырылды; мәдрәсә мөгаллимнәре аттестация үтте, ксенофобик һәм экстремистик агым-юнәлешләргә каршы төрле чаралар күрелде.

Узган ел Россиядә тәүге тапкыр Татарстан Диния нәзарәте һәм Россия ислам университеты белән бергәлектә Имамнарның белемен күтәрү үзәге ачылган иде. Аллага шөкер, үзәктә узган уку елы дәвамында ике йөзгә якын муллабыз белемен ныгытты. Бу уку елы башлануга әлеге үзәк янә имамнарның белемен күтәрү өстендә эшен дәвам итә. Инде көзен биредә берничә район имамнары укып китте.

Диния нәзарәте каршында "Хәләл" стандартлар комитеты эшләп килә. Комитет белән хезмәттәшлек итәргә алынучы предприятиеләр саны арта бара. Җирлектәге оешмалар белән эшләүдән тыш, актив рәвештә халыкара симпозиумнарда, очрашуларда, рәсми сәфәрләрдә катнашу күзәтелә. Халыкара оешмалар белән элемтәләргә нигез салына бара. Моннан тыш, экспорт һәм импорт хәләл продукциягә контроль оештырыла башлады. Мәсәлән, Греция, Австралия, Уругвай илләреннән кертелгән хәләл итләрнең чынлап та хәләл булу-булмавына комитет экспертлары күзәтчелек итә. "Хәләл" комитеты үз эшчәнлеген республика, Россия төбәкләре белән генә чикләми, төрле чит илләр белән килешүләр төзеп алып баруны да бүгенге көн таләбе итеп куя.

Нәзарәтнең "Зәкят" фонды ел дәвамында мохтаҗларга ярдәм күрсәтте, күп сандагы акцияләр, чаралар оештырды.

Диния нәзарәте үзенең хаҗ программасын булдырылды. Быелгы хаҗ аккредитация узган "Хезмәт-тур" һәм "ДУМ РТ Хадж" туроператорларына аша оештырылды. Беренче туроператор аша - биш йөзләп мөселман, ә икенчесе аркылы Татарстан, шулай ук Сембер, Самара һәм башка өлкәләрдә яшәүче меңнән артык милләттәшебез юллама алды. Оештыручылар һәм хаҗилар сүзләреннән аңлашылганча, агымдагы ел хаҗы югары дәрәҗәдә үтте. Казаннан туп-туры Мәдинәгә оча торган авиарейслар оештыруда да уңыш елмайды. Сәфәр алдыннан без Казанда һәм республикабызның төрле районнарында хаҗга әзерлек буенча лекцияләр үткәрдек. Дин сабаклары шулай ук Мәккәдә дә уздырылды. Мәдинәдә хаҗилар Әл-Хәрам мәчетеннән 100-150 метр ераклыкта гына урнашкан 4-5 йолдызлы кунакханәләрдә яшәделәр. Аларны ашату өчен бушлай "швед өстәле" оештырылды. Быелгы хаҗның тагын бер үзенчәлекле ягы күзәтелде: татар халкының барлык гореф-гадәтләрен истә тотып, корбан ашы оештырылды. Хаҗилар арасыннан булган Коръән-хафизлар Коръән укыдылар. Мәккәдә хаҗ кылган арада Изге Китапны тулысынча укып чыктылар. Хаҗны тиешле дәрәҗәдә оештырып чыгару өчен өлеш керткән барлык хәзрәтләргә дә рәхмәт белдерәбез.

Яшьләр белән эшчәнлекне дә аерым әйтеп үтү кирәк. Лениногорск, Мамадыш, Яңа Чишмә, Буа, Бөгелмә районнарында "Алтын урта" мөселман яшьләре җәмгыятенең филиаллары барлыкка килде, Ураза һәм Корбан гаетләрендә төрле акцияләр, файдалы чаралар уздырылды, һәрбер районда актив яшьләр мөхтәсибәт тирәсенә җыйнала башлады. Киләсе елда әлеге филиалларны калган районнарда да ачып, яшьләр эшчәнлеген көчәйтеп җибәрергә кирәк. Ни генә дисәк тә, яшьләр - милләтнең киләчәге, ә әхлаклы яшьләр - милләтнең өмете. Шуны онытмасак һәм яшьләр белән эшчәнлеккә аеруча зур игътибар юнәлтсәк иде.

Аерым дини газеталар чыгара торган мөхтәсибәтләр дә бар, сайтларның да саны артканнан-арта бара. Диниагарту эшен массакүләм мәгълүмат чаралары аркылы да алып бару мөһим. Интернет ресурсларда, матбугат чараларында үзебезнең күркәм эшләребезне чагылдырып бару - шулай ук безнең бурыч булып тора.

Бүгенге җәмгыятебезгә бердәмлек җитмәве үзен нык сиздерә: дөньяда булган тарткалашулар, бәла-казалар барысы да бердәмлек булмаудан килә. Әмма дин әһелләре арасында тынычлык, татулык иң беренче урында булырга тиеш. Үзебезнең гамәлләребез белән генә түгел, һәр сүзебез, тоткан кыйблабыз белән моны расларга, берберебезгә хәерхаһлы булырга тиешбез.

Бер-беребезгә карата битарафлык булырга тиеш түгел: бүген бер имамга сүз тидерсәләр, иртәгә сезгә дә пычрак атмаслар дип кем гарантия бирә ала? Шуңа да бербөтен булып эшләү, һәрберебездән уяулык сорала. Имамхатыйб, мөхтәсиб, казый, мөфти һ. б. - без барыбыз да бер юлда, Аллаһы Тәгаләнең кушканнарын халыкка җиткерү юлында хезмәт куябыз. Әйтик, дисбенең бер гәрәбәсе генә төшсә дә, ул дисбе булудан туктаган кебек, безнең дә беребезгә генә тискәре сүз әйтсәләр дә, барыбызга да кагыла, шуны онытмасак иде. Сезнең эшчәнлектән канәгать түгелләр икән - бергәләшеп киңәшик, тел тидерәләр икән - сәбәбен карыйк, дөрес булмаган очракта уртага салып фикерләшик. Бердәм булган очракта гына динебезне үстерә, иманыбызны ныгыта, кыйблабызны саклый алачакбыз.

Барлык имамнарга, имам-мөхтәсибләргә, казый һәм республикабызда динебезне үстерүгә, ныгытуга, таратуга үзләреннән өлеш кертеп килә торган фидакарь затларга, нәтиҗәле эшләре өчен, олуг рәхмәтләребезне җиткерәм. Киләсе елларда да динебезнең асыл кыйммәтләрен үстереп, киләсе буынга тапшыруга барлык көчебезне куярбыз дип ышанып калам. Аллаһы Сөбханәһү вә Тәгалә куелган максатларыбызга ирешергә, бергәләшеп мөселман өммәтен үстерергә, ныгытырга, дини кыйммәтләрне күтәрергә насыйп әйләсә иде.

**Үзәкләшкән дини оешма -**
**Татарстан мөселманнары**
**Диния нәзарәте рәисе,**
**мөфти Илдус хәзрәт ФӘИЗ**

# Әбелмәних Каргалыйның суфичылык шигъриятендә Коръән мотивлары

***(Дәвамы. Башы газетабызның 7 декабрь (№23) санында.)***

Уртача позицияләрдә тору - Идел-Урал суфичылыгының үзенчәлекле төп сыйфаты. Иран суфичылыгы өчен оппозиционлык хас; гарәп суфичылыгы регламентар характер йөртә, анда бу мистик тәгълимат дин эченә кереп бикләнергә тырыша. Ә Идел-Урал суфичылыгы бу өчберлек арасында Аристотельнең "алтын урталыгында" тора. "Тарикате игътидалә" ("Уртача тарикать") - сөннәтнең кырыйлыкларга юл куймау юлы, ул Идел-Уралга Урта Азия дин үзәкләреннән (Бохара, Сәмаркандтан) китерелгән. Бу тәгълиматның нигезенә хәнәфи мәзһәбе тарафдары Хуҗа Әхрарның (Гобәйдулла Әл-Әхрар, 1404-1490) өйрәтмәләре салынган. Ул: "Сиңа боерылганнарда - ныклы һәм какшамас бул! Барысында да урталыкта торырга тырыш!" - дигән.

Суфи шагыйрь Ә.Каргалыйның иҗатында күп кенә бөек пәйгамбәрләр тормышы белән бәйле Коръән сюжетлары да бар:

Хәзрәти Ягъкуб галәйһе-с сәлам
Кем намаз укыр икән, әндәр кыям
Күз очыйлә Йосфа андәк нәзар
Әйләде бер көнне ул хәйре-л бәшар.
Хак Тәгалә әйләде ул дәм хитаб,
Ягъни Исраилә әзруй гыйтаб:
"Бәндин үзгәя мәхәббәт мәйлене
Кыйлдыгың чөн мөбтәля идәм сәне!
Бу сәбәптин күзләреңне кур итәм,
Фиркате Йосыф илә мәһҗүр итәм!"

[Хазрат Якуб, мир ему,
В то время, как читал намаз он стоя,
Краем глаза взглянул на сына своего, Юсуфа -
Так поступил лучший из людей.
В тот же миг Всевышний с речами обратился
К Исраилю, в лицо ему упрёк Он бросил:
"За то, что в любви своей ты предпочёл Меня другому,
Тебя на бедствия Я обрекаю!
По причине этой сделаю тебя незрячим,
С Юсуфом также разлучу тебя Я!"]

Монда автор укучының игътибарын суфичылыкның ике төп категориясенә: матурлыкка, гүзәллеккә (әл-җамал) һәм мәхәббәткә (әл-мәхәббә) юнәлтә. Мәхәббәт һәм матурлыкның берлеге - суфичылык эстетикасында төп юнәлеш булып бара. Суфилар фикере буенча, "мәхәббәт" һәм "матурлык" категорияләре бер-берсенә шулкадәр тыгыз бәйләнгән: әгәр дә мәхәббәт юкка чыкса, матурлык та югала. Мәхәббәт үз чагылышын матурлыкта һәм матурлык аша таба. Мәсәлән, Җами матурлыкның мәхәббәттән күп тапкырлар өстенрәк булуын күрсәтеп яза:

Сөю-гүзәллек зынҗырларында һәрчак таза.
Гүзәллек хаким, ә сөю - кол аңа,
Хаким гүзәллек килеп чыкты исә,
Сөю аның аяк астына башын ия.

[Любовь в оковах красоты всегда чиста.
Любовь - раба, царица - красота.
Когда выходит красота-царица,
Любовь к её ногам упасть стремится.]

Әлбәттә, һәр шагыйрь яки язучы бу төшенчәләргә үзенең аерым бер мәгънәсен сала, әхлакый мәгънә эстетик мәгънәдән өстенлек алырга да мөмкин, яки киресенчә дә була. Суфиларда, кагыйдә буларак, эстетиклыкның үзен әхлакыйлыктан аерып карау, гадәттә, кыен. Ләкин, Ә.Каргалыйда, күрүебезчә, әхлаклылык - билгеләүче, төп категория булып билгеләнә.

Суфичылыкның әл-Газзәлидән (1059-1111) башлап, Румига (1207-1273) һәм Җамига (1414-1297) кадәрге бар теоретикларының да матурлык, гүзәллек турындагы карашлары Аллаһны мистик аңлау идеясенә нигезләнгәннәр, чөнки, гүзәллек ул - Аллаһның камиллеге чагылышы. Һәм Ә.Каргалыйның шигырендә Аллаһ үзенең пәйгамбәре Ягъкубка шелтә белән мөрәҗәгать итә: "Үз сөюеңдә син башканы Миннән өстенрәк күрдең". Йосыф - ул бит гаҗәеп чибәр һәм сөелгән зат. Ләкин абсолют гүзәллекккә бары тик Аллаһ кына ия, һәм шуңа да, мөселман этикасы буенча, намаз укыган вакытта (ә ул вакытта гыйбадәт кылучы кешенең җаны Аллаһка якынлаша) башка чит әйберләргә игътибар итәлергә тиеш түгел. Алга таба автор гади кешеләргә, үз замандашларына мөрәҗәгать итеп, үз фикерләренә нәтиҗә чыгарып куя:

Мондыйн отры улачак билә гыйтаб,
Хәлемез гайне хараб, әндәр хараб!
Нәчә күрә күземез дидарыны?!
Җан(у) деллә сәүәрез әгъярыны.
Ике сөюкү чөнки җәмгъ улмаз бәһәм,
Дип боермыштыр рәсуле мөхтәрәм.

[Сильнее этого (во сто крат)
гнев Господа выльется на нас,
Тяжка участь наша, ох тяжка!
Ужель достойны узреть мы Божий лик?!
Мы, что душой и телом врага Его возлюбили.
Истинно, двум любовям вместе не бывать, -
Так заповедал благословенный наш Пророк.]

Күрүебезчә, Ә.Каргалый Ягъкуб пәйгамбәр турындагы Коръән сюжетына бик оригиналь интерпретация бирә.

**Алсу ХӘСӘВНЕХ,**
**филология фәннәре кандидаты,**
**Г.Ибраһимов исемендәге**
**Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының язма**
**һәм музыкаль мирасны өйрәнү үзәгенең өлкән**
**фәнни хезмәткәре**

# ЯПОНИЯГӘ ИСЛАМ ДИНЕН ИРЕШТЕРГӘН ШӘХЕС



***"Әссәламегаләйкем! Хөрмәтле җаваплы мөхәррир! Сезнең сәхифәгезнең берсендә Токио каласыннан Юта Хасияма исемле студент белән әңгәмә урнаштырылган иде. Анда сүз ислам диненең Япониягә үтеп керүе, беренче мәчет салынуы турында барган иде. Әйе, дөрестән дә бу эшнең башында безнең милләттәшләребез торган. Шул хакта искә алабыз икән, безнең атаклы милләттәшебез - XX гасырның башларында татар иҗтимагый тормышында зур урын алып торган бер шәхесне яд итмичә үтү гаделсезлек булыр иде. Мин биредә Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимовны (1857-1944) халык арасында "Рәшит казый" дигән даны таралган күренекле галим-эзләнүче, ислам динен таратучы, миссионер, нәшир, сәяхәтче, язучы һәм публицистны истә тотам. Кем соң ул Рәшит Ибраһимов? Ислам динен таратуда аның өлеше нидән гыйбарәт? Япония кебек "ябык" илдә мөселман өммәте оештырып, гыйбадәтханә салуга ул ничек ирешкән? Әлеге сорауларга җавапны мин "Татар зыялылары / Татарские интеллектуалы" (Казан: Магариф, 2005) дип аталган китаптан эзләп таптым. Шушы язманы укучылар игътибарына тәкъдим итсәгез иде. Габдерәшит Ибраһимовның туууына быел 155 ел тулганын да исегезгә төшерәм".***

**Рәхим РӘШИТОВ,**
**журналист**



Ибраһимов Габдерәшит Гомәр улы 1857 елның 23 апрелендә Тубыл губернасы Тара шәһәрендә сәүдәгәр гаиләсендә туган. Башлангыч белемне туган төбәгендәге мәктәп-мәдрәсәләрдә ала. 1877 елдан Казан артының данлыклы Кышкар мәдрәсәсендә укый. 1879-1884 елларда Мәдинә шәһәрендә дин гыйлемен үзләштерә, Коръән-хафиз дәрәҗәсенә ирешә. 1885 -1892 елларда Тара каласының Җәмигъ мәчете имамы һәм мөдәррис була. 1892 елда Оренбургта Диния нәзарәтенең казые итеп сайлана. 1895 елдан эмиграциядә. Истанбулда "Чулпан йолдызы" китабын бастыра. Бу китапта Россиянең патша хакимиятенең татарларны руслаштыру сәясәтен бик нык тәнкыйтьли. Мөфти М.Солтановны моңа каршы бернинди чара күрмәүдә, бары тик үз мәнфәгатьләрен кайгыртуда гаепли. Аны царизмның агенты дип атый. "Чулпан йолдызы" китабының икенче басмасы 1907 елда Санкт-Петербургта басылып чыга. 1897-1900 елларда Г.Ибраһимов чит илләр буйлап сәяхәт кыла. Ул Истанбул, Мисыр, Хиҗаз, Фәлистыйн, Иран, Франция, Италия, Австрия, Сербия, Болгария, Россиянең көньяк төбәкләре, Кавказ, Каспий диңгезе буйлары, Бохара, Төркистанда була. Россиягә әйләнеп кайткач, Г.Ибраһимов иҗтимагый-сәяси эшчәнлек белән шөгыльләнә. 1900-1908 елларда Санкт-Петербургта аның нәширлегендә "Миръат", "Нажәт" журналлары, "Өлфәт" газетасы, "ат-Тилмиз" атналыгы нәшер итеп таратыла.

Бу басмаларда патша администрациясенең илнең мөселман халыкларына карата алып барылган астыртын христианлаштыру, руслаштыру сәясәте фаш ителә, ислам динен ныгыту һәм үстерү, мәгърифәт, тарих, мәдәният мәсьәләләре киң яңгыраш таба. "Мөселман иттифакы" фиркасенең Петербургтагы секциясенең рәисе итеп сайлана. Рәсми хакимият тарафыннан эзәрлекләүгә дучар була. 1907 елда Төркистанга сәяхәт кыла, мәдрәсәләр эше белән кызыксына, укыту һәм шәкертләрне тәрбияләү мәсьәләләре белән таныша. 1908 елда Казан, Уфа, Чиләбе, Петропавловск, Омск, Томск, Өркет аша Монголия, Маньчжурия, Харбин, Владивосток аша Япониягә барып чыга. Биредә югары катлам даирәләре, хәрбиләр белән ныклы элемтәләр һәм хезмәттәшлек урнаштырып, аларны ислам динен кабул итәргә күндерә. 1909 елда Кореягә китә, Кытай, Сингапур, Һиндстан аша Истанбулга кайта. Сәяхәт вакытында алган тәэсирләрен "Ислам дөньясы" дигән китабына кертә. 1911 елда, Италия белән Төркия арасында сугыш барганда, яшерен рәвештә Төньяк Африкага - Триполига барып чыга.1912 елда Көнбатыш Төркистан, Бохара, Әфганстан һәм Хиҗазга сәяхәт кыла. 1916 елда Берлин янындагы Зоссен лагерендә мөселман әсир солдатларының лагеренда була. 1917 елда Дөньякүләм конференция барган көннәрдә Стокгольмда була. 1919 елда Мәскәүдә һәм Казанда, 1919-1921 елларда Себернең Тубыл, Омск, Тара калаларында чыгышлар ясый. Көнчыгыш Төркистанга сәяхәт итә. Җирле мөселман халыкларын - уйгур, казах, татарларны милли азатлык өчен көрәшкә өндәп, ялкынлы чыгышлар ясый. Төркиягә әйләнеп кайта һәм 1931 елда кабат хаҗ кыла. 1933 елда янә Япониягә бара һәм 1937 елда Токиода Җәмигъ мәчете төзеп, шунда имам була. 1939 елда Япониядә ислам дине рәсми рәвештә дәүләт дине дип раслана. 1944 елның 31 августында вафат була. Җәсәде Токио янындагы мөселман зиратына җирләнә.

***ФОТОЛАРДА: 1) Рәшит казый; 2) Габдерәшит Гомәр улы Ибраһимовның истәлегенә куелган кабер ташы.***

## Казанда намаз вакытлары

| Көн исеме | Дата | Иртәнге намаз | Кояш чыгу | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| Шимбә | 15.12.12 | 7:38 | 9:08 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Якшәмбе | 16.12.12 | 7:39 | 9:09 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Дүшәмбе | 17.12.12 | 7:39 | 9:09 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Сишәмбе | 18.12.12 | 7:40 | 9:10 | 13:02 | 15:07 | 16:10 | 17:40 |
| Чәршәмбе | 19.12.12 | 7:41 | 9:11 | 13:02 | 15:08 | 16:11 | 17:41 |
| Пәнҗешәмбе | 20.12.12 | 7:41 | 9:11 | 13:02 | 15:08 | 16:11 | 17:41 |
| Җомга | 21.12.12 | 7:42 | 9:12 | 13:02 | 15:08 | 16:11 | 17:41 |
| Шимбә | 22.12.12 | 7:43 | 9:13 | 13:02 | 15:09 | 16:12 | 17:42 |

# НУХ ГАЛӘЙҺИССӘЛАМ ҺӘМ АНЫҢ УЛЫ

**Адәм галәйһиссәламнән соң шактый вакытлар үтте. Кешелек нәселе арткannan-арта барды. Һәм алар Адәм галәйһиссәлам өйрәтеп калдырган бер Аллаһка гына гыйбадәт кылу диненнән тайпылдылар. Кайберләре - күктәге йолдызларга, икенче берләре изге кешеләрнең сурәтләрен ясап, аларны Аллаһ урынына куеп табына башладылар. Аларны хак дингә өндәр өчен Аллаһы Тәгалә Нух галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп җибәрә. Һәм ул адашкан кавемен туры юлга чакыру вазифасын вәгазь һәм нәсыйхәт белән башлап җибәрә. Әмма потка табынып теләсә нәрсә эшләп яшәгән кешеләр Нух галәйһиссәламнең сөйләгән сүзләренә әһәмият бирмичә, мәсхәрәләп, сөйләгән сүзеннән көлеп, аны кире кагалар.**

### Нух пәйгамбәрнең кешеләргә сөйләгән кайбер вәгазьләре һәм нәсыйхәтләре

"Әй, кавемем, мин сезнең өчен ачык кисәтүче генә. Аллаһы Тәгаләнең берүзенә генә гыйбадәт итегез. Ул тыйган әйберләрдән тыелыгыз, боерыкларын үтәгез. Әгәр дә шулай эшләсәгез, Ул сезнең гөнаһларыгызны гафу итәр. Билгеләнеп куйган әҗәлегезгә кадәр сезне газапламас. Һәм шуны белегез: Аллаһы Тәгалә сезнең өчен билгеләп куйган үлемне беркем дә кичектерә алмас. Шуны аңласагыз иде. Әгәр дә сөйләгән сүзне аңлап яхшы якка үзгәрсәгез, Аллаһы Тәгалә сезнең өчен күктән мул иттереп яңгырлар иңдерер. Малларыгызны һәм балаларыгызны арттырыр. Яхшы итеп үсә торган бакчалар, киң иттереп ага торган елгалар насыйп итәр. Ни өчен сез Аллаһы Тәгаләнең бөеклеген танып, Аңа табынмыйсыз? Ул бит сезне бер хәлдән икенче хәлгә кертеп юктан бар итте. Әллә күрмисезме, ничек итеп Аллаһы Тәгалә җиде кат күкне кат-кат итеп яратты. Айны - нур, кояшны яктылык бирә торган итте. Аллаһы Тәгалә иксез-чиксез кодрәте белән үсемлекләрне яраткан кебек, сезне дә җир матдәсеннән яратты. Соңыннан кире сезне җиргә кайтарып, Кыямәт көнендә кире җирдән чыгарыр. Һәм сез Җир йөзендә авырлыкларсыз йөрсен өчен, сезнең каршыгызга җәймә кебек җирне җәйде", - диде Нух галәйһиссәлам һәм башка бик күп хикмәт тулы сүзләр сөйләде.

Әмма ләкин, Нух галәйһиссәламнең вәгазен ишетеп, бик азлар иман китерде. Нух пәйгамбәр 950 ел дәвамында төрледән-төрле ысуллар белән кавемен хак дингә өндәү нәтиҗәсендә, бармак белән генә санарлык кешеләр аның артыннан иярде. Алары да фәкыйрьләр, гариплләр, мохтаҗлар иде. Нух галәйһиссәламне мәсхәрә итүчеләр үзләренең балаларына, Нух пәйгамбәргә бармаклары белән күрсәтеп: "Теге ак сакаллы юләрне күрәсезме? Ул акылсызның сүзен тыңлап ахмакланмагыз", - дип әйтә иделәр.

Иң соңыннан, дингә өндәүнең бер файдасы юк икәнлекне күргәч, ул Аллаһы Тәгаләгә сыкранып ялварды:

- Әй Раббым, кавемем минем сүземне тыңламады. Хәсрәтләрен арттыра торган әйберләр артыннан иярделәр. Маллары да, балалары да аларга үкенечтән башка бернәрсә бирми торган әйберләргә кызыкты. Миңа һәм иярченнәремә карата олы-олы мәкерлекләр, яшерен дошманлыклар күрсәттеләр. Берберсенә: "Нух галәйһиссәламнең сүзен тыңлап табынган потларыгыздан ваз кичә күрмәгез", - диештеләр. Күпләре адаштылар. Әй Раббым, ул залимнәрнең дошманнарын арттырганнан-арттыр.

Соңыннан: "Гөнаһлары сәбәпле алар батырылырлар. Һәм утка кертелерләр. Аллаһтан башка аларга ярдәм итүче һич тә булмас", - диеп, Нух галәйһиссәлам түбәндәге доганы кылды:

- Раббым, Җир йөзендә кяферләр яшәгән бер җирне дә калдырма. Берсен генә булса да калдырсаң, алар синең колларыңны адаштырыр һәм алардан - гөнаһлы кяферләрдән башка, һичкем тумас.

Аллаһы Тәгалә аңа хәбәр итте:

- Бер зур кораб төзе. Корабны төзеп бетергәннән соң, һәрбер хайванны парлы итеп шунда җый. Синең артыңнан ияргән иман китерүчеләрне коткарырмын. Сине мәсхәрәләгән барлык имансыз бәндәләрне су астында калдырып, барысын да һәлак итәрмен.

Нух пәйгамбәргә Аллаһы Тәгаләнең шушы боерыгы килеп ирешкәннән соң, ул шунда ук кулына кораб ясый торган кораллар алды һәм эшкә керешә. Имансыз бәндәләр Нух галәйһиссәламнең комлы чүл уртасында кораб ясый башлавын күргәч, көлүләрен, аны мәсхәрә итүләрен тагы да арттырдылар. Хәтта үзенең хатыны белән улы да имансыз булу сәбәпле, "Әтиебез - Нух галәйһиссәлам - чыннан да, бөтенләй акылдан шашты", - дип бөтен җиргә сүз тараттылар.

Нух галәйһиссәлам кораб ясаган вакытта аның янына килеп:

- Әй, юләр карт, берәр нәрсә була калса, безгә дә берәр урын калдырырсың инде, - дип көлә иделәр.

- Күпме булдыра аласыз, шулкадәр көлегез, мәсхәрәләгез. Тиздән кемнең хәле тагын да көлкелерәк икәнлекне күрерсез, - дип җавап кайтара иде Нух галәйһиссәлам.

**(Дәвамы газетабызның киләсе саннарында.)**

**Мәхмүт хәзрәт ШӘРӘФЕТДИН,**
**Казан шәһәре казые,**
**Борисководагы**
**Шамил мәчете имам-хатыйбы**

**«Дин вә мәгыйшәт» газетасы. № 24 (167) чыгарылыш.**
**Гамәлгә куючы һәм нәшир:** Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте.
**Баш мөхәррир:** Ришат ХӘМИДУЛЛИН.
**Мөхәррир:** Нияз САБИРҖАНОВ.
**Дизайнер:** Рөстәм МИҢНУЛЛИН.
**Тираж:** 5000 данә. **Заказ:** 9429.

**Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - 3,00 сум.**
**Редакция адресы:** 420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27.
***График буенча бу санга 13 декабрь көнне 17.00 сәгатьтә кул куелырга тиеш иде. Кул куелды – 17.00 сәгатьтә.***
*Теркәлү турында таныклык: Татарстан матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 елның 16 февралендә 240 нчы номер белән теркәлде.*
**Электрон адрес:** niyaz.kazan@yandex.ru **Тел.:** 8(843)267-29-67.

Газета "Татмедиа" ААҖ филиалы – "Идел-Пресс" полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты (420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2).

**Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Коръәннән аятьләр бар, тиешсез урынга кулланудан саклангыз!**